КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 11 февраль г.Казань № 110

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының «Сәләт - Ак Барс» яшьләр үзәге» дәүләт автоном учреждениесе төзү турында

«Автономияле учреждениеләр турында» 2006 елның 3 ноябрендәге 174-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт (муниципаль) учреждениеләрнең хокукый хәлен камилләштерүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 18 маендагы 820 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләрен төзү, үзгәртеп оештыру, төрен үзгәртү һәм бетерү тәртибен билгеләү, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре мөлкәтен гамәлгә куючының һәм аның милекчесенең функцияләрен һәм вәкаләтләрен регламентлау өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2010 ел, 18 май, 820 нче карары белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының «Сәләт - Ак Барс» яшьләр үзәге» дәүләт автоном учреждениесе (алга таба - Учреждение) төзү турында Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Учреждение эшчәнлегенең төп максаты итеп балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын гамәлгә ашыруны билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгын автоном учреждение мөлкәте милекчесе функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы итеп билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына:

Учреждениене гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкарырга;

30 көн эчендә Учреждение уставын расларга һәм законнар нигезендә кирәкле башка оештыру чараларын үтәргә;

Учреждениенең күзәтү советы составын расларга;

Учреждение уставын раслаганнан соң 10 көн эчендә эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте исемлеген Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына тапшырырга;

ел саен уставта каралган төп эшчәнлек төре нигезендә Учреждение өчен дәүләт йөкләмәсен һәм финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын расларга.

5. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына күчемсез мөлкәткә Татарстан Республикасы милекчелеге хокукын теркәгән көннән алып 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтенең оператив идарәсе хокукындагы Учреждениене, шул исәптән Учреждение эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәтне, беркетергә.

6. Учреждение тарафыннан дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанс белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел,  31 декабрь, 1044 нче карары белән билгеләнгән тәртиптә, күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы бюджетында каралган чаралар чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

7. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә Учреждение уставын раслаганнан соң 60 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга дәүләт яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2021 ел, 07 сентябрь, 837 нче карары белән расланган 2022 елга дәүләт яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт учрежде-ниеләренең норматив чыгымнарына үзгәрешләр кертү хакында» карары проектын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

8. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　А.В.Песошин